ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.1А, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур., 1А йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **Постановление**

27.09.2018 № 19

**Референдум уздыру инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Башкарма комитеты К А Р А Р БИРӘ:

1.Үзара салым акчаларын күчерү мәсьәләләре буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

“Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру: Уразбахты торак пунктында урамнарны яктырту объектларын модернизацияләүгә (агымдагы ремонт, җирлек территориясендә урам утлары лампалары сатып алу һәм алмаштыру) өчен” каралган, 2016 елда гражданнардан җыелган үзара салым акчасының 154,5 мең сум күләмендә калган өлешен “Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру: Уразбахты торак пунктының Комсомол урамы юлларын вакташ җәеп ремонтлау” өчен үзгәртелүенә сез ризамы:

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Шәйхетдинов Р.Г.